ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 13 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 26 (I өлеш); 2022, № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 2 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә килеп чыга торган хәвефләр» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында килеп чыга торган хәвеф-хәтәр (алга таба – хәвеф-хәтәр)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) халыкны эвакуацияләү, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклау;»;

в) 6 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халык өчен куркыныч туган» сүзләрен «хәвеф-хәтәр барлыкка килгән» сүзләренә алмаштырырга;

г) 7 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «хәвеф-хәтәр барлыкка килү аркасында» сүзләренә алмаштырырга;

д) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) хәвеф-хәтәр барлыкка килү аркасында килеп чыккан янгыннарга каршы көрәшү;»;

е) 11 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «хәвеф-хәтәр барлыкка килү аркасында» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 14 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләрен «хәвеф-хәтәр барлыкка килгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$) гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы җитәкчесе тәкъдиме буенча тулы күләмдә яисә өлешчә Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планын гамәлгә кертә;»;

3) 7 статьяның 1 өлешендә:

а) 2 пунктта «, коткару хезмәтләрен төзи» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктта «халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләүне әзерләү, аларны урнаштыру» сүзләрен «халыкны эвакуацияләүгә әзерләү, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклауга әзерләү һәм яклау» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органнары;»;

5) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары һәм гражданнар оборонасы көчләре эшчәнлеген координацияләү**

Федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары һәм гражданнар оборонасы көчләре эшчәнлеген координацияләү Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

6) 12 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Федераль закон нигезендә гражданнар оборонасы буенча республика дәрәҗәсендәге аерым чараларны финанс белән тәэмин итү тәртибе, шулай ук мондый чараларның исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 20 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 03 гыйнвар
№ 1-ТРЗ